ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.12.2019 Казан шәһәре № 11-30/тко

«Полигон» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә каты коммуналь калдыкларны күмүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2017 № 10-76/кс карарында билгеләнгән озак сроклы чик тарифларга 2020 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2020 елга каты коммуналь калдыкларны күмүгә озак сроклы тарифларны үзгәртү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Полигон» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2018-2020 елларга чик дәрәҗә тарифлар билгеләү турында» 01.12.2017 № 10-76/кс карарына (Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының 21.11.2018 № 10-36/кс карары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын башкаручы Л.П.Борисова

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
01.12.2017 № 10-76/кс карарына
1 нче кушымта (Татарстан
Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының 11.12.2019
№ 11-30/тко карары редакциясендә)

2018-2020 елларга «Полигон» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә календарь бүлеп бирелгән чик тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/куб.метр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | Биектау муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «Полигон» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 78,46 | 78,46 | 78,46 | 105,27 | 92,86 | 92,86 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2017 № 10-76/кс карарына 2 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 11-30/тко карары редакциясендә)

## 2018-2020 елларга «Полигон» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары

| т/с | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Полигон» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | |
| 1.1 | Каты коммуналь калдыкларны күмү | 2018 | 4745,52 | 1 | - | 0,08 |
| | | 2019 | 7514,74 | 1 | - | 0,08 |
| | | 2020 | 7662,79 | 1 | - | 0,08 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге